КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 8 декабрь г.Казань № 1059

2026 елның су басу куркынычы булган чорында Татарстан Республикасы территориясендә ташкын суларының тискәре йогынтысын һәм зыяннарын булдырмау чаралары турында

2026 елның язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, гидротехника корылмаларын, юлларны һәм күперләрне саклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2026 елның су басу куркынычы булган чорында Татарстан Республикасы территориясендә ташкын суларының тискәре йогынтысын һәм зыяннарын булдырмау чаралары планын (алга таба – План) расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, Татарстан Республикасының барлык дәрәҗәләрдәге янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләренә, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм Планда күрсәтелгән оешмаларга – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

План чаралары үтәлешен тәэмин итүне;

гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләре белән җитәкчелек итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары нигезендә гамәлгә ашыруны;

2026 елның 1 апреленә кадәр Планны тормышка ашыру турындагы мәгълүматны һәм 2026 елның 15 маена кадәр ташкын узу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына кертүне.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына 2026 елның 1 июненә кадәр 2026 елда Татарстан

Республикасы территориясендә язгы ташу узу нәтиҗәләре турында мәгълүмати-аналитик хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елның су басу куркынычы булган чорында Татарстан Республикасы территориясендә ташкын суларының тискәре йогынтысын һәм зыяннарын булдырмау чаралары турында» 2025 ел, 31 гыйнвар, 47 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 8 декабрь, 1059 нчы
карары белән расланды

2026 елның су басу куркынычы булган чорында Татарстан Республикасы территориясендә ташкын суларының тискәре йогынтысын һәм зыяннарын булдырмау чаралары планы

| Т/с | Чараның исеме | Башкаручылар | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Оештыру чаралары | | | |
| 1. | 2026 елгы язгы ташуга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен әзерләү чаралары үтәлешен тикшерү графигын төзү | Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХһЯКТИК) эшче төркеме, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (алга таба – Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча БИ) (килешү буенча) | 2026 елның 5 мартына кадәр |
| 2. | Язгы ташу салган зыяннарны киметү һәм бетерү өчен кичектергесез чаралар күрүне таләп итә торган мәсьәләләрне даими рәвештә карап тикшерү | Татарстан Республикасы ГТХһЯКТИКнең эшче төркеме, Татарстан Республикасы ГТХМ | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 3. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын | Татарстан Республикасы ГТХһЯКТИКнең эшче төркеме, Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия ГТХМның | ташкын башланганга |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләренә (алга таба – муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИК) су басуга каршы һәм аны кисәтү чараларын әзерләүдә һәм үткәрүдә оештыру-методик ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы буенча БИ (килешү буенча) | кадәр һәм ташкын чорында |
| 4. | Су басуга каршы чараларны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча методик һәм гамәли ярдәм күрсәтү максатларында республиканың су басу ихтималы булган зонага туры килә торган торак пунктларына Татарстан Республикасы ГТХМ хезмәткәрләре баруны оештыру | Татарстан Республикасы ГТХМ, Татарстан Республикасы ГТХһЯКТИКнең эшче төркеме | 2026 елның 20 мартына кадәр |
| 5. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына көтелә торган су басу тасвирнамәләрен, Татарстан Республикасы елгаларында суның максималь дәрәҗәләре фаразын, елгаларны ачу һәм сусаклагычларны чистарту сроклары фаразларын бирү | «Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «Татарстан Республикасы ГММИ» ФДБУ) (килешү буенча) | 2026 елның 15 мартына кадәр |
| 6. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә су объектларының агымдагы торышы турында мәгълүматлар (көндәлек мәгълүмат гидрометеорология бюллетене кысаларында) бирү | «Татарстан Республикасы ГММИ» ФДБУ (килешү буенча) | ташкын чорында |
| 7. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына Идел-Кама каскады сусаклагычында су арту фаразларын бирү | «Татарстан Республикасы ГММИ» ФДБУ (килешү буенча) | 15.03.2026 – 01.06.2026 |
| 8. | Республика территориясен су асты җирләре күтәрелү аркасында су басу ихтималы булган зоналар буенча районнарга бүлү һәм барлыкка килә торган метеошартлар турындагы белешмәләр нигезендә ташкынның аеруча мөмкин булган фараз исәп-хисап сценарийларын һәм үсеш модельләрен һәм аның начар | Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | сценарийларын әзерләү | | |
| 9. | Республиканың су объектларында су дәрәҗәсен, куркыныч һәм авария хәлендәге гидротехника корылмаларының торышын тикшерүдә тоту өчен вакытлыча күзәтү челтәре (гидрология постлары) эшчәнлеген оештыру | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) (килешү буенча), муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИК (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр |
| 10. | Ташкынның ни рәвешле үтүенә бәйле фараз һәм мониторинг гидрометеорология мәгълүматларын тапшыруны үз вакытында һәм тулысынча тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Россия ГТХМның Татарстан Республикасы буенча БИ (килешү буенча) | ташкын чорында |
| 11. | 2026 елның су басу чорына әзерлек мәсьәләсе, халыкның тормыш эшчәнлеген беренчел чиратта тәэмин итүне оештыру буенча муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИК утырышларын үткәрү. Үткән елларның ташкын узу нәтиҗәләрен исәпкә алып, ташкынга каршы үткәрелгән чараларны бәяләү | муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИК (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ | 2026 елның 20 мартына кадәр |
| 12. | Ташкын сулары басу ихтималы булган зоналардан халыкны, авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм матди кыйммәтләрне өлешчә эвакуацияләү (күчерү) планнарын тәгаенләү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 20 мартына кадәр |
| 13. | Ташкын чорында муниципаль берәмлекләрнең ГТХһәмЯКТИК, халыкны һәм территорияләрне саклау буенча оператив төркемнәр гамәлләре күнекмәләрен үткәрү | муниципаль берәмлекләрнең ГТХһәмЯКТИК рәисләре (килешү буенча) | 2026 елның 20 мартына кадәр |
| 14. | Халыкка һәм муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИКнә хәбәр итү системаларының эшкә сәләтен тикшерү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 15 мартына кадәр |
| 15. | Су басу зонасына эләгә торган торак пунктлар белән радиоэлемтәне оештыру, элемтә көчләрен һәм чараларын исәпләүне башкару | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 15 мартына кадәр |
| 16. | Сыек калдыклар туплану, агулы химикатлар саклану | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать | язгы ташу |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | һәм чистарту корылмалары урыннарында өске катлам суларның сыйфатын контрольдә тотуны оештыру | ресурслары министрлыгы (вәкаләтләр кысаларында), Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) | чорында |
| 17. | Муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИК эшче (оператив) төркемнәрен формалаштыру һәм аларның әзерлеген тәэмин итү | Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча БИ (килешү буенча) | 2026 елның 15 мартына кадәр |
| 18. | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына 2026 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территорияләрен саклау чараларына җәлеп ителә торган көчләр һәм чаралар турында белешмәләр бирү | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасы ГММИ» ФДБУ (килешү буенча) һәм җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 1 февраленә кадәр |
| 19. | Язгы ташу аркасында гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда халыкка үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен җиткерү | Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча БИ (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 20. | 2026 елда Татарстан Республикасы территориясендә язгы ташу чорында хәвеф-хәтәрләрне йомшарту һәм гадәттән тыш хәлләргә реакция ясау планына төзәтмәләр кертү | Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия Федерациясе ГТХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 15 февраленә кадәр |
| 21. | 2026 елгы язгы ташу чорында муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары һәм Татарстан Республикасы халкын һәм территорияләрен саклау чараларына җәлеп ителә торган оешмалар арасында үзара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыру турындагы | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 1 мартына кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | килешүләргә төзәтмә кертү | | |
| 22. | Гидротехника корылмаларында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм эшкәртү, шулай ук кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар арасында әлеге мәгълүмат белән алмашу | Татарстан Республикасы ГТХМ | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 23. | Муниципаль берәмлекләрнең бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләре гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасындагы тиешле муниципаль звенолар составына керә торган ведомстволар, оешмалар белән күнегүләр үткәрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | аерым план буенча |
| 24. | Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының идарә органнары һәм көчләре белән су басу куркынычы булган чорда төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдәге гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча комплекслы күнегүләрне оештыру һәм уздыру | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 31 мартына кадәр |
| 25. | Язгы ташуга, табигать янгыннарына, торак пунктларны, икътисад һәм социаль инфраструктура объектларын урман янгыннарыннан саклауга бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү мәсьәләләрен җентекләп өйрәнү, шулай ук урман янгыннарын сүндерү өчен билгеләнгән көчләр һәм чаралар белән төбәкара маневрлау мәсьәләләрен җентекләп өйрәнү буенча бергәләп уздырыла торган комплекслы укуларда катнашу | Россия ГТХМның Татарстан Республикасы буенча БИ (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХһЯКТИК, Татарстан Республикасы ГТХМ, дәүләт хакимиятенең территориаль органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары һәм оешмалары (килешү буенча) | 2026 елның II кварталы |
| 26. | Россия ГТХМның Түбән Новгород өлкәсе буенча баш идарәсе җитәкчелегендә язгы ташуны һәлакәтсез үткәрү мәсьәләләрен җентекләп өйрәнү буенча штаб күнегүләре үткәрү | Россия ГТХМның Татарстан Республикасы буенча БИ (килешү буенча) | 2026 елның I кварталы |
| Гамәли чаралар | | | |
| 1. | Кечкенә елгаларның участокларында боз тыгылган | Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча БИ | язгы ташу |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | урыннарны бетерү буенча шартлату эшләрен үткәрүне оештыру | (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ | чорында |
| 2. | Гидротехника корылмаларын (инженерлык саклагыч объектларын, буаларны, плотиналарны, дамбаларны һ.б.) максималь күләмдә кар суларын агызып җибәрүгә әзерләү эшләрен башкаруны оештыру, шулай ук, су төбендәге су чыгарыла торган урында задвижкаларны ачып һәм көйләп, сусаклагычларның (буаларның) күләмен кышкы (куркынычсыз) минималь дәрәҗәгә кадәр киметү юлы белән гидротехника корылмаларын гидравлик эш режимында тоту | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалар (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 10 мартына кадәр |
| 3. | Боз һәм боз кисәкләре тыгылуны барлыкка килүне кисәтү, боз ваклауны оештыру, гидротехника корылмаларының барлык фронты буенча су агызу тишемнәре аша боз өемнәрен үткәреп җибәрү | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалары (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу чорында |
| 4. | Су басулар иненсив булу фаразланган очракта, инженерлык саклагыч корылмаларына күзәтчелек итүне көчәйтү, тәүлек буе кизү торуны, хәбәр итүнең һәм элемтәнең ышанычлы системасын оештыру | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалары (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 5. | Татарстан Республикасы су объектларының боз тыгылу куркынычы булган участокларда бозны каралту һәм кисү эшләрен башкаруны оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның марты |
| 6. | Җир асты сулары күтәрелеп су басуга дучар булган торак пунктлар янында, авиация техникасын кулланып, халыкка ярдәм күрсәтү өчен вакытлыча вертолет мәйданчыкларын (мөмкинлек булганда) әзерләү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 1 мартына кадәр |
| 7. | Муниципаль берәмлекләрнең бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләрен гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасына караган муниципаль звено составына керүче оешмаларның, | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 1 мартына кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | ведомстволарның кизү-диспетчерлык хезмәтләре, җаваплы вазыйфаи затлары турында мәгълүматлар бирелгән актуаль телефон белешмәлекләре белән тәэмин итү | | |
| 8. | Ремонт барышында җибәрелгән бозуларны һәм кышкы чорда салынган тискәре зыяннарны үз вакытында ачыклау һәм бетерү максатларында мелиорация системаларын һәм гидротехника корылмаларын кабат тикшерү | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалар (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 25 мартына кадәр |
| 9. | Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә халыкка һәм территориягә куркыныч тудыра торган, куркынычсыз эксплуатацияләнүен тәэмин итеп булмый торган гидротехника корылмаларын тикшерү | гидротехник корылмаларның милекчеләре һәм аларны эксплуатацияләүче оешмалары (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 20 мартына кадәр |
| 10. | Су ресурслары федераль агентлыгының Идел-Кама каскады сусаклагычларының эш режимнарын җайга салу буенча ведомствоара эшче төркемгә су басу алдыннан булган һәм су басу чорларында сусаклагычларның оптималь дәрәҗәләренә ирешү өчен Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының эш режимнарын билгеләү турында тәкъдимнәр әзерләү | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы ГТХМ | 2026 елның 1 июненә кадәр |
| 11. | Якын тирәдәге территорияләрне су басуны булдырмау буенча үз вакытында чаралар күрү һәм су басу куркынычы булган очракта халыкка хәбәр итү өчен сусаклагычларның билгеләнгән эш режимын саклауны контрольдә тоту | Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны сулары идарәсенә караган Татарстан Республикасы буенча Су ресурслары бүлеге (килешү буенча), «Центррегионводхоз» федераль дәүләт бюджет су хуҗалыгы учреждениесенең «Средволгаводхоз» филиалы (алга таба – «Средволгаводхоз» филиалы) (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ | ташкын чорында |
| 12. | «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасы, «Татарстан Республикасы территориясендә су | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары | 2026 елның 1 маена кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | басулардан һәм суларның башка тискәре йогынтыларыннан саклау, гидротехник корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү» төбәк проекты, «Татарстан Республикасының су хуҗалыгы комплексын үстерү» төбәк проекты кысаларында 2026 елда капиталь ремонтланырга тиешле гидротехник корылмалар исемлеген төзү | | |
| 13. | Аерым план буенча расланган исемлек нигезендә гидротехник корылмаларга, шулай ук милек хокукы теркәлмәгән гидротехник корылмаларга комиссион тикшерү үткәрү (тапшырылган кабул итү-тапшыру актлары буенча). Гидротехник корылмаларны тикшерү актларын төзү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ, Россия ГТХМның Татарстан Республикасы буенча БИ (килешү буенча) | 2026 елның 30 апреленә кадәр |
| 14. | Су объектларының су саклау зоналарын пычратуга һәм язгы ташу суларының сыйфатын начарайтуга юл куймау буенча (бигрәк тә сыек калдыклар туплана торган районнарда, чистарту корылмалары һәм агулы химикатлар саклау, елгаларның һәм сулыкларның боз өстенә автотранспорт керү, ведомстволар причаллары һәм елга транспортының төяү-бушату урыннарында) оештыру чараларын һәм инженер-техник чаралар үткәрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (вәкаләтләр кысаларында), «Средволгаводхоз» филиалы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | оештыру чаралары – 2026 елның 15 мартына кадәр, гамәли чарала – ташкын чорында |
| 15. | Ветеринария-санитария таләпләре нигезендә ташкын сулары басу ихтималы булган зонага эләккән авыл хуҗалыгы объектларын һәм үләт базларын (шул исәптән түләмә авырулы терлекләр күмелгән урыннарны) тикшерү. Үләт базларын су басуны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне оештыру | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 1 апреленә кадәр |
| 16. | Кар суларын максималь күләмнәрдә агызып җибәрү өчен шәһәрләрдәге һәм районнардагы юлларда су үткәрү торбаларын, яңгыр суы агу урыннарын, каналларны, яңгыр сулары канализациясе корылмаларын, минераль ашламалар һәм агрохимикатлар саклану урыннарын | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – «Главтатдортранс» ДКУ), «Федераль юл агентлыгының | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | чистарту чараларын үткәрүне оештыру | Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесе (алга таба – «Волго-Вятскуправтодор» ФКУ) (килешү буенча), «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясенең Казан филиалы (алга таба – «Автодор» дәүләт корпорациясенең Казан филиалы) (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | |
| 17. | Су басу ихтималы булган зонага эләккән электр челтәре комплексы объектларына (электр тапшыру линияләре, ярдәмче станцияләре, трансформаторлы ярдәмче станцияләренә), газ бүлү челтәрләренә тикшерү үткәрү. Аларны имин эксплуатацияләү буенча чаралар күрү | «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе (килешү буенча), «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) | 2026 елның 25 мартына кадәр һәм ташкын чорында |
| 18. | Күперләрне тикшерү һәм ныгыту, аларны торгызу өчен материаллар һәм чаралар әзерләү. Су өстенә якын салынган, аеруча куркыныч булган ясалма корылмаларга махсус контроль билгеләү. Вакытлыча кичүләрне һәм аркылы чыгу урыннарын билгеләү | «Главтатдортранс» ДКУ, «Волго-Вятскуправтодор» ФКУ (килешү буенча), «Автодор» дәүләт компаниясенең Казан филиалы (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 19. | Автоюлларның һәм ясалма корылмаларның язгы ташу чорында эшләргә әзерлеген һәм аларны карап тоту дәрәҗәсен билгеләү буенча тикшерүләр оештыру | «Главтатдортранс» ДКУ, «Волго-Вятскуправтодор» ФКУ (килешү буенча), «Автодор» дәүләт компаниясенең Казан филиалы (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 20. | Су басу ихтималы булган зоналарга эләккән торак биналардан һәм халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү системалары объектларыннан кар суларын агызып җибәрү эшләрен оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 25 мартына кадәр һәм ташкын чорында |
| 21. | Коммуналь хуҗалык объектларында язгы ташу китереп | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм | 2026 елның |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | чыгарган гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының авария-техник запасыннан матди-техник чараларны оператив бирүне тәэмин итү | торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 25 мартына кадәр һәм ташкын чорында |
| 22. | Йөзү чараларын, инженерлык, юл-төзелеш техникасын һәм башка кирәкле техниканы кичектергесез һәлакәт-торгызу эшләрен үткәрү очрагына әзерләү, аны кирәкле күләмдә ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 20 мартына кадәр |
| 23. | Гадәттән тыш хәлләрне һәм алар салган зыяннарны бетерү өчен түбәндәгеләрне булдыру:<br>финанс, матди-техник чаралар;<br>инертлау һәм сорбентлау материаллары | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 20 мартына кадәр |
| 24. | Ташкын чорында зыян күргән кешеләргә медицина ярдәме күрсәтүне оештыру буенча әзерлек эшләрен үткәрү. Медицина ресурслары резервын даими яңартып тору | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 1 апреленә кадәр |
| 25. | Ташкын чорында зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген беренче чиратта тәэмин итүгә әзерлек эшләрен башкару | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 1 апреленә кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 26. | Суның сыйфаты начарайганда кичектергесез чаралар күрү өчен эчә торган сыйфатлы су әзерләү предприятиеләрендә зарарсызландыру чараларының, реагентларның өстәмә запасларын (кимендә бер ай эшләрлек) булдыруны тәэмин итү. Җитештерү лабораториясе шартларында су белән тәэмин итү чыганакларындагы суның сыйфатын һәм халыкка бирелә торган эчәргә яраклы суның сыйфатын контрольдә тотуны көчәйтү, су алу корылмаларының санитар ышанычлылыгын һәм туфракта су йөрү горизонтының сакланышын бәяләү | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), су белән тәэмин итү һәм су чыгару объектларының милекчеләре һәм балансta тотучылары (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 27. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне мелиорацияләүне үстерү» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2026 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән плотиналарны һәм гидротехник корылмаларны проектлау, төзү, реконструкцияләү, торгызу, капиталь ремонтлау эшләрен үз эченә ала торган гидротехник корылмаларны торгызу буенча мелиорация эшләре исемлеген раслау | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, «Идел буе федераль округы буенча Җирләр мелиорациясе һәм авыл хуҗалыгы су белән тәэмин итү идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 15 маена кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 28. | Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларын су баскан, җир асты сулары күтәрелеп су баскан очракта, яшәүче халык санын исәпкә алып, эчәргә яраклы суны алып килү өчен шартлар тәэмин итү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 29. | 2026 елгы язгы ташу чорында боз шартлату эшләрен башкарганда шартлаткыч материалларны алып бару өчен «Татарстан Республикасы ГТХМ каршындагы Татарстан Республикасының Эзләү-коткару хезмәте» дәүләт казна учреждениесе автомобилен әзерләү | Татарстан Республикасы ГТХМ | 2026 елның 10 апреленә кадәр |
| 30. | Халыкны үзәктән ераклаштырылган су белән тәэмин итү чыганакларына су керүне, су басуны кисәтүгә юнәлдерелгән профилактика чаралары үткәрү. Су баскан, җир асты сулары күтәрелеп су баскан очракларда, норматив документлар нигезендә аларны юу һәм дезинфекцияләү буенча чаралар күрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 31. | Йорт биләмәләре территорияләрен, шул исәптән санитар узелларны, чокып ясалган һәм ишегалды бәдрәфләрен су баскан, җир асты сулары күтәрелеп су баскан очракта, йорт биләмәләре янындагы территорияләрдә дезинфекция чараларын үткәрү буенча чаралар күрү. Махсуслаштырылган оешмалар белән дезинфекция чараларын үткәрү өчен алдан шартнамәләр төзү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | ташкын беткәннән соң |
| 32. | Халыкның тормыш эшчәнлеген беренчел чиратта тәэмин итүне оештыру өчен кирәкле мөлкәт булган вакытлыча урнаштыру пунктлары әзерлеген тикшерүне оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2026 елның 25 мартына кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 33. | Муниципаль берәмлек территориясендә гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычы булганда яки килеп чыкканда елга юлларының үткәрү сәләтен торгызу чараларын оештыру («Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге законнар нигезендә гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычы булганда яки гадәттән тыш хәл килеп чыкканда елга юлларының үткәрү сәләтен торгызу, елга төбәннән алынган туфрак катлавын файдалану эшчәнлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2024 елның 31 маендагы 732 номерлы карары нигезендә) | муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИК, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (вәкаләтләр кысаларында), «Средволгаводхоз» филиалы (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 34. | Шартлаткыч матдәләрне һәм шартлату чараларын транспорт белән алып барганда озатып йөрүне, шулай ук Татарстан Республикасының су объектларында боз тыгылган урыннарны бетерү буенча шартлату эшләрен башкару урыннарын әйләндереп алу | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына (килешү буенча) | язгы ташу чорында |
| Контроль чаралар | | | |
| 1. | Торак-коммуналь, юл, энергетика, медицина предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренең су басу чорына әзерлеге турында докладларын тыңлау | муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИК (килешү буенча) | 2026 елның 25 мартына кадәр |
| 2. | 2026 елда ведомствоара комиссия тарафыннан муниципаль берәмлекләрнең су басу куркынычы булган чорга әзерлеген сайлап контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча БИ (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ | 25.02.2026 – 05.03.2026 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3. | Эчә торган суның сыйфатына, халыкны эчә торган су белән тәэмин итүгә файдаланыла торган ачык су чыганакларының, су алу җайланмаларының торышына санитария-эпидемиология тикшерүен оештыру | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), су белән тәэмин итү һәм су чыгару объектлары милекчеләре һәм аларны баланста тотучылар (килешү буенча) | 2026 елның 15 маена кадәр |
| 4. | Муниципаль берәмлекләрнең ГТХһЯКТИК тарафыннан әлеге План чаралары үтәлешен сайлап контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | 2026 елның 1 апреленә кадәр |
| 5. | Ведомство буйсынуындагы предприятиеләрнең һәм оешмаларның язгы ташу чорында халыкны һәм территорияләрне саклау чараларын үткәрүгә әзерлеген һәм сыйфатын тикшерүдә тотуны оештыру | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары | 2026 елның 1 апреленә кадәр |
| 6. | Халыкка су объектларының факттагы һәм көтелә торган торышы, торак пунктларны һәм икътисад объектларын су басу ихтималы, халыкның иминлегенә куркыныч янау турында үз вакытында хәбәр итү | «Татарстан Республикасы ГММИ» ФДБУ (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ һәм Россия ГХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча) | ташкын башланганга кадәр һәм ташкын чорында |
| 7. | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына һәм Россия ГХМ Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә 2026 елда Татарстан Республикасы су объектларында язгы ташуның үтү үзенчәлекләре турында аналитик белешмә бирү | «Татарстан Республикасы ГММИ» ФДБУ (килешү буенча) | язгы ташу чоры тәмамланганнан соң |

---